Раслыйм:
Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе
Д.М. Анварова

Район оешма-предприятиеләре, уку-укыту учреждениеләре, авыл җирлекләре арасында узачак

**Яңа ел бәйрәме тамаша - бәйгесенең нигезләмәсе**

**“Борын заман түгел, хәзер заман**
**Олы куян – балаларны , кунак җыйган....”**

**Бәйгене гамәлгә куючы**

-Актаныш муниципаль районы
-Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты
- Район башкарма комитетының мәгариф бүлеге

**Оештыручылар**

- Район башкарма комитетының социаль һәм агарту бүлеге
- Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге

**Бәйгенең бурычы**

Яңа ел бәйрәм көннәрендә район җирлегендә яшәүче балаларның ялын файдалы һәм кызыклы итү максатыннан тәрбияви мәдәни чараларга тарту.

Халык әкиятләре, милли геройлары аша, балаларда әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү , камилләштерү, зыялы чын гражданин итеп тәрбияләү;

- балаларны инсафлы, әдәпле, мәрхәмәтле, кешелекле, ярдәмчел итеп үстерү;

- туган илне, туган җирне, туган якны, туган телне белү, ярату ,өйрәнү, саклау;

- чыгышларда, бизәлешләрдә, костюмнарда үзебезнең мультфильм, кино, Зарубин В.И открыткалары геройларына өстенлек бирү.

**Бәйгенең эчтәлеге**

Район үзәгендәге барлык уку-укыту учреждениеләре, оешмалары, авыл җирлекләре ( 7 халык-театрлары коллективларыннан башка) командалары катнаша.

Алар: кыш бабай, кар кызы ( 10-14 яшь) һәм 5 куян баласы ( 10-12 яшьлек балалар) белән катнашалар (кулларында Россия флажогы һәм ясалган күгәрчен тоту мәҗбүри)

9.00-9.30 Админстрация бинасы янында Кыш бабайлар, Кар кызлары, куяннар регистрация үтә, шунда флешмобта катнаша

9.30-9.45 Үзәк чыршы янына парад ясап Юбилейный урамы буенча киләләр

9.45-10.00 Күмәк хоровод. Хоровод эчендә һәр оешма, җирлекләрнең командалары дефиле күрсәтә (алып баручы таныштыргач, һәр команда үзенә генә хас матур сүзләр, хәрәкәтләр белән сәламли - үз генә хас фишка ясый)

10.00-10.30. Кыш бабайлар чыгышы (бу вакытта тройкалар урый) кар кызлары һәм куян балалары күмәкләшеп бииләр ( Җырның сүзләре һәм көе бирелә)

10.30-10.45 Куяннар чыгышы (Җырның сүзләре һәм көе бирелә)

11.00 **Авыл җирлеклекләре халык театрларының** кызыклы бәйрәм котлаулары, шаян чыгышлары башлана ( Халык әкиятләренә , совет чоры мультфильмнарына нигезләнеп эшләргә)

Тема**:**

**"Борын заман түгел, хәзер заман**
**Олы куян – балаларны кунак җыйган...."** ( 3 минут)

Җиңүчеләр билгеләнеп бүләкләр тапшырыла.